وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№23 (166). 7 декабрь 2012 / 23-мөхәррәм-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Азан кемгә яңгырый дип сорамагыз... ▷2◁



Ә. Каргалыйның суфичылык шигъриятендә Коръән мотивлары ▷3◁



Пычрак гайбәтләр корбаны булдым... ▷4◁

# Кыямәт көне

**Кыямәт көненә карата безнең динебезнең карашы нинди? Кыямәт көненең ае, елы, сәгате төгәл билгелеме, юкмы? Безнең төп дини чыганакларыбыз икәү: Аллаһы Тәгаләнең китабы - Коръәни-Кәрим һәм шулай ук Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) сөннәте. Алардагы мәгълүматны тикшереп карасак, аятьләргә күз салсак, күрәбез - бу проблеманың тарихы 1400 ел элек үк булган. Заманында мөшрикләр пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) янына сорау белән киләләр. Алар әйтәләр: "Бу вәгъдә ителгән көн кайчан?" Пәйгамбәребез (сгв) беренче көнне үк, аңа Аллаһы Тәгаләдән дәгъват кылырга боерык килгәндә үк Сафа тавына менеп, Мәккә халкын үзе янына чакыра. Халык җыелгач, Пәйгамбәребез (сгв) болай ди: "Әгәр дә мин сезгә хәбәр бирсәм, шушы тау артында сезгә һөҗүм итәргә әзер гаскәр тора дисәм, сез миңа ышаныр идегезме?" Бөтенесе җавап бирә: "Әйе, без сиңа ышаныр идек. Син безнең арабызда әмин буларак танылган. Без синнән беркайчан да ялган сүз ишетмәдек. Кыямәт көне җитеп, Сезне Аллаһы Тәгаләнең газабыннан коткарыр өчен, мин сезгә пәйгамбәр итеп җибәрелдем". Димәк, Пәйгамбәребез (сгв) дәгъватының беренче көнендә үк Кыямәт көне турында кешеләргә хәбәр бирә. Иман китермәгән кешеләр Пәйгамбәребезгә (сгв) сорау бирә башлыйлар. Ул син вәгъдә иткән көн кайчан, әгәр дөрес сөйләүче булсаң, безгә аның тарихын, кайчан булачагын хәбәр ит. Сорау булгач, Аллаһы Тәгаләдән җавап көтелә. "(Кяферләр мыскыллы киная белән): "Сөйләгәннәрегез хак булса, вәгъдә иткәннәрегез (Кыямәт көне, газаплар) кайчан киләр? - диярләр" ("Мөлек (Падишалык)" сүрәсенең 25 нче аяте). Башка аятьтә Раббыбыз безгә бик файдалы мәгълүмат бирә: "Шөбһә юк ки, Кыямәт Сәгатенең кайчан сугачагын бары тик Аллаһ кына белә. Яңгырны Ул яудыра. Ана карынында ни барлыгын Аллаһ белә. Иртәгә ни кылачагын (ни казаначагын, корган тәдбирләренең уңышлымы, уңышсызмы булачагын) һичкем белми. Кеше үзенең кайда үләчәген белми. Шик юктыр ки, Аллаһ бөтенесен белеп тора. Ул барысыннан да хәбәрдар" ("Локман" сүрәсенең 34 нче аяте). Шулай ук, бу китерелгән аятьләрне безгә Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисе исбатлый. Көннәрдән беркөнне шулай ук Кыямәт көненең кайчан булачагы турында сорау бирелгәч, аның җавабы бик кыска була: "... Мин Кыямәт көне белән менә шундый якынлыкта җибәрелдем", - дип, ике бармагын күрсәтә, башка хәдисләрдә килгәнчә, ул ике бармагын аермаган, ә кушкан. Димәк, безнең динебезнең җавабы бар. Сорау туа: дөнья бетү турындагы сүз каян килеп чыкты соң? Әгәр газеталарны укысак, телевизорны карасак, анда җавабы бар:**



**безгә хәтле Америка җирлегендә яшәгән, Майя индеецлары махсус дини-тәкъвый календарь алып барганнар. Араларында гыйлемле кешеләр булган ахрысы, календарьларе төгәл, бик дөрес саналган. 2012 елда аларның календарьларе бетә, диелгән. Моны галимнәр ачыкладылар инде, ә менә гыйлемнәре зәгыйфьрәк булган кешеләр моның тирәсендә ыгы-зыгы тудыра башлады: календарьларе бетә икән, дөнья бетә имеш. Аларның сүзләренә колак салып, Кыямәт көненә әзерләнергә кирәк икән дип нәтиҗә ясадылар. Әмма дә ләкин чынбарлыкны тикшереп карыйк, кадерле дин кардәшләрем, чыннан да акыллы кешеләр булдылармы икән алар? Аларның тарихларын өйрәнүче галимнәр шундый мәгълүматлар җиткерә: имеш, ул халыкның бүгенге футболга ошаган бер уеннары булган, ул туп белән уйналган, әмма туп урынына еш кына кеше башларын кулланганнар. Менә шундый дәрәҗәдә булган бу халык. Шул сәбәпле, үзегез нәтиҗә ясагыз, мондый халыкның мәгълүматларына ышанырга буламы? Монда әле тагын бер сорау туа. Кыямәт көненең кайчан булачагын белү безгә берәр нинди файда китерәме, юкмы? Хәер, монысы сөйләшү өчен аерым бер тема.**

*Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,*
*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары*

# Пәйгамбәребезнең (сгв) нәфис теле

**Барча мактауларыбыз Аллаһы Тәгаләгә булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!**

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) теленең күркәмлеге, җыйнак һәм шул ук вакытта тулы мәгънәле булуы - бөеклеге һәм пәйгамбәрлегенең иң ачык дәлилләреннән берсе. Ул анык һәм дөрес сөйләм теленә, хикмәт тулы булган хак сүзләргә, онытылмаслык могҗизаларга ия булган. Аллаһы Тәгалә аның сөйләменең пакьлеге турында болай ди:

"Ул артык кызып, һавалы сөйләшмәс. Ул вәхий ителгәннәрне генә сөйләр" ("Нәҗем (Йолдыз)" сүрәсенең 3-4 нче аятьләре).



"(Аллаһның колларын) кисәтүче (үгетче) булсын дип, синең күңеленә (Коръән) иңдерелде. (Җиңел аңлашылырлык булсын дип) гарәпчә ачык итеп иңдерелде" ("Шөгарә (Шагыйрьләр) сүрәсенең 194-195 нче аятьләре").

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән: "Миңа кыска, ләкин эчтәлекле сөйләм бирелгән" (Мөслим, әт-Тирмизи). Ул шулай ук: "Гарәпләр арасында иң күркәм теллесе мин", - дигән. Бу горурлык белән әйтелгән сүзләр түгел, ә фәкать башкаларны сөйләменә карата булган фикерләр белән таныштыру өчен генә әйтелгән сүзләр. Күңеленә Изге Коръән иңдерелгән, Дөньялар Хакиме тәрбияләгән соңгы пәйгамбәр ничек күркәм сөйләмле булмасын, ул бит шигъриятле сөйләмгә ия булган гарәпләр арасында туып үскән.

Шагыйрьләр, язучы һәм галимнәр Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) гүзәл сөйләмен тасвирлап бирүдә үзара ярыша торган булганнар. Әбу Госман әл-Җаһиз (Урта гасырлар гарәп әдәбиятының иң мәшһүр вәкилләреннән берсе, 869 елда вафат) үзенең "Әл-бәйән вә-т-табйин" ("Ачыклык һәм аңлатулар") китабында шулай дип язган: "Аның сөйләме сүзләрнең күп булмавы,

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**"МӨХӘММӘДИЯ"НЕҢ ОЕШУЫНА ТИЗДӘН 130 ЕЛ ТУЛА**

**17 декабрь көнне "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең оешуына 130 ел тула.** Шул уңайдан, Г.Камал ис. Татар дәүләт академия театрында бәйрәм чарасы узачак. Юбилей тантанасында төрле мөнәҗәтләр, вәгазьләр, яшьләр иҗаты, мәдрәсә тарихы, анда тәрбияләнгән шәхесләр белән танышу мөмкинлеге булачак.

Билгеле булганча, беренче мәдрәсә 1882 елда Галимҗан Баруди тарафыннан оештырыла. Ул 36 ел эчендә бик күп шәкертләргә белем бирә. 1918 елда ябыла. Бинасы башка оешмаларга бирелә. 1993 елдан мәдрәсә татар руханилары тарафыннан ачыла. Башта мәдрәсә Ленин ис. мәдәният йортында урнашкан була. Аннары төрле биналарга күченеп йөри, 1998 елда элеккеге бинага күчерелә. Хәзерге вакытта мәдрәсә Казан шәһәрендәге Габдулла Тукай урамында урнашкан.

**МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕНЕҢ IV СПАРТАКИАДАСЫ (СТРИТБОЛ) УЗДЫ**

**4 декабрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Казан шәһәре муниципаль берәмлегендәге физик тәрбия һәм спорт комитеты белән берлектә, мөселман яшьләре арасында стритбол буенча шәһәр спартакиадасы оештырды.**

"Ватан" спорт комплексында узган чарада РИУ, "Мөхәммәдия", Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәләрдән, Солтан, Әниләр, Гали мәчетләреннән спортчылар катнашты.

I урынга - РИУ спортчылары, II урынга - "Мөхәммәдия" шәкертләре, III урынга - Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре лаек дип табылды.

Җиңүчеләргә дипломнар, медальләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**АПАНАЙ МӘЧЕТЕНДӘ ИШЕТМӘҮЧЕЛӘРНЕ ИСЛАМ НИГЕЗЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТӘ БАШЛАЯЧАКЛАР**

**"Иман" ислам мәдәнияте үзәге Казанның Апанай мәчетендә мәчет-мәхәллә игътибарыннан читтә калган социаль төркемне - ишетмәүчеләрне ислам нигезләренә өйрәтү эшен башлап җибәрә.**

Бу хакта "Иман" мәркәзе җитәкчесе, "Апанай" мәчете имам-хатыйбы Наил хәзрәт Гарипов Татарстанның ишетмәүчеләр җәмгыяте рәисе Венера Матеш белән очрашып сөйләште. Н.Гарипов белдергәнчә, ишетмәүчеләр белән эшләү "Иман" мәркәзенең яңа эш юнәлешләренең берсе булачак, бу эшчәнлек инвалидларга җәмгыятьтә үз урыннарын табарга булышачак.

Ишетмәүчеләрне 15 ел эчендә беренче тапкыр мәчеткә кунакка чакырганнары да билгеле булды. Сөйләшү барышында Наил хәзрәт инвалидларга ислам дине турында вәгазь сөйләде. Намаз уку, гаилә кору мәсьәләләренә тукталды. Мәҗлестән соң инвалидлар "Касыймия" мәдрәсәсендә урнашкан Вәлиулла Якупов музее белән танышты.

Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Азан кемгә яңгырый дип сорамагыз...

**Ислам белән без, иң беренче тапкыр, бу дөньяга килгәч үк очрашабыз. Гаилә өчен аеруча истәлекле көнне, балага исем кушу көнен төшереп алган фоторәсемнәр һәр мөселман гаиләсе фотоальбомында да диярлек бар. Алар - безнең бу дөньяда Ислам белән беренче очрашуыбыз.**



Урнашкан гадәт буенча, исем кушу йоласын, кагыйдә буларак, өйдә үткәрәләр. Якыннарның һәм туган-тумачаның котлаулары, мул итеп әзерләнгән өстәл, дога уку... Тик бу йоланың үзәк мизгеле - имамның яңа туган нарасыйга азан һәм камәт укуы. Азан һәм камәт укылганнан соң, имам, аның ата-анасы сайлап алган исемне баланың колагына өч тапкыр әйтә: "Синең исемең <...> булсын. Исемең синең <...> Синең исемең <...>". Шуңа да, кайвакыт, балага исем кушуны "балага азан әйтү" дип әйтәләр дә. Кече яшьтән үк Ислам гореф-гадәтендә тәрбияләнгән кеше яңа туган нәни кешегә укылган бу азанны аерым бер илтифат һәм эчке дулкынлану хисләреннән башка тыңлый алмый.

Совет атеизмы елларында бу йоланың мәгънәсе турында без уйланып та карамый идек. Азанмы, "Ясин"мы, безнең өчен, серлелек белән уратып алынган, ниндидер бер әфсенле, аңлаешсыз сүзләр җыелмасы кебек тоела иде. Без үзебез гадәтләнгән йолаларны шулай булырга тиеш икәнен белеп кенә үткәрә идек. Ә бу ни өчен кирәк соң? Әлеге йолаларның мәгънәсе нидә? Бу турыда без сораштырып та тормый идек. Хәзер инде без "Ясин" Коръәндәге 36 нчы сүрә - "Коръәннең йөрәге" икәнен беләбез. Бүгенге көндә авылның мәктәпкәчә яшьтәге һәр баласы да, азан ишетелгәч, бабайның мәчеткә барырга тиешлеген, чөнки азанның көйгә салынган ниндидер сүзләр генә түгел, ә намазга чакыру икәнен белә. Ә якшәмбе мәктәпләрендә булса да уку бәхетенә ирешә алганы, хәзерге вакытта, азан белән камәт арасында ачык чик үткәрә ала. Ул: "Азан - намазга чакыру, ә камәт - аның фарыз өлешенә чакыру була", - дип әйтәчәк.

Ләкин, күпләрдә бик тә урынлы бер сорау килеп туарга мөмкин: ни өчен  исем кушу йоласы вакытында бары тик азан һәм камәт кенә әйтелә, ә намаз укылмый? Бу сорауга җавапны йоланың үзеннән эзләргә кирәк. Анда алар, чынлап та, юк. Ләкин, әле бу, һич тә азан һәм камәтнең ниндидер бер дога рәвешендә генә укылуын аңлатмый. Юк, алар төгәл үз билгеләмәләре буенча, ягъни, намазга, өстәвенә аның фарыз өлешенә чакыру булarak укылалар. Ләкин, балага исем кушканда аларның - ул намазларның - укылмаганын без хәтерлибез. Парадокс - кабул ителгән кануннарга каршылык килеп туа!

Килеп туган бу каршылыкны аңлату максатыннан, кешенең тууына, ягъни аның тормышы башланган вакытка түгел, ә аның тормышының ахырына, ягъни аның вафат булган вакытына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Туган вакытта аңа бик озын тормыш теләнгән бу сабый, үзенең тормыш юлын үтеп, кешеләр аны соңгы юлга озатырга җыенган вакытта гына аның балалыктан алып гомер буена сакланып йөртелгән әлеге сере ачыла. Белүебезчә, мәрхүмгә җеназа намазы укыла. Дини кыйммәтлелегә буенча - бу фарыз намаз. Ләкин аның алдыннан бар фарыз намазларга да таләп ителгән азан да, камәт тә әйтелми.

Һәм менә шул барысын да аңлата да инде: яңа туган балага укылган азан һәм камәт, беркая да юнәлтелмәгән чакырулар түгел, ә аны җирләгәндә укыла торган намазга, аның җеназа намазына чакыру. Башка сүзләр белән әйткәндә, исем кушу йоласының мәгънәсе кешенең бар тормышы дәвамында һәм дә ахырында ачыклана торган башы гына. Башкача да әйтергә була: безнең бар тормышыбыз бары бер йола гына, әлеге йоланың ахырына әзерләнү - намазга  чакыру белән намаз үзе - дөньяга туу белән Безне Яралтучы алдында очрашу арасындагы бер мизгел генә. Безнең бар тормышыбыз Аллаһка юл.

**Азан кемгә яңгырый дип сорамагыз...**

**Сиңа, миңа, аңа яңгырый ул азан.**

***Рөстәм хәзрәт БАТЫР,***
***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы рәисе,***
***Россия ислам университетының фәнни эшләр буенча проректоры***

# Коръән укучылар көч сынашты

**1 декабрь көнне Россия ислам университетында республикакүләм Коръән укучылар конкурсы узды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан уздырылган бәйге республикабыз районнарында Коръән укучылар бәйгеләрендә җиңеп чыкканнарны бергә җыеп, аларга өч номинация буенча сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек бирде.**



"Коръәннең 30 җүзеннән яртысын белү" номинациясендә Азнакай районыннан Илнар Зарипов беренчелекне алса, "Коръәннең 30 нчы өлешен белү" ("Гаммә" җүзе) номинациясендә Теләче районыннан Ислам Кәбиров җиңү яулады, "Коръәнне дөрес уку" номинациясендә Сарман районыннан Илнур Сабуров беренче урынга лаек дип табылды.

Буа районыннан килгән Руслан Сабиров исә "Республикакүләм Коръән конкурсы"нда Гран-прига лаек дип табылды һәм планшет белән бүләкләнде.

Барлык катнашучыларга да затлы китаплар, дисклар тапшырылды, җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр (I урын алучыларга - цифрлы фотоаппарат, II урынга - электрон китап, III урынга - мәгълүматны туплап бара торган USB-флеш) бирелде.

Бәйгенең жюрилары составында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең нәшрият бүлеге җитәкчесе Камил хәзрәт Сәмигуллин, РИУ каршындагы Коръән-хафизлар үзәге җитәкчесе Ибраһим хәзрәт Сабиров, шулай ук РИУ мөгаллимнәре, Коръән-хафизлар бар иде.

Конкурсның ябылу тантанасында РИУ ректоры, сәясәт фәннәре докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин: "Коръәнне белгән яшьләр югары әхлакка ия, шуңа да әлеге бәйгегә игътибарны арттырырга кирәк. Киләчәктә җәмгыятебезнең үсешенә, камилләшүенә дә ул зур өлеш кертәчәк", - дип билгеләп үтте.

Бәйгедә катнашучылар соңыннан Россия ислам университетындагы Коръән-хафизләр үзәгенең эшчәнлеге белән танышты, җиңүчеләргә әлеге үзәккә имтихансыз керү хокукы бирелде.

# Пәйгамбәребез (сгв) ни рәвешле юмарт булган?

**Пәйгамбәребезнең (сгв) киеп йөргән күлмәге бик искерә, искелектән хәтта ертыла башлый. Ул өендә булган бердәнбер дүрт дирһәм акчасын кесәсенә салып, яңа бер күлмәк алу өчен базарга китә. Күлмәген сатып ала һәм өенә кайта, шуннан соң иске күлмәген салып, яңасын кигән генә була, кемдер ишеккә шакыганны ишетә. Ишекне ачып җибәргәннән соң, Пәйгамбәребез (сгв) үз каршында бер фәкыйрьне күрә. Бу адәм:**



- Әй Мөхәммәд (сгв), мин синең базарда яңа күлмәк сатып алганыңны күрдем. Минем күлмәгем синекеннән дә искерәк. Аллаһ ризалыгы өчен миңа шул күлмәгеңне бир әле, - дип сорый.

Пәйгамбәребез (сгв) күлмәген салып аңа тоттыра һәм янәдән күлмәк алу өчен базарга юнәлә. Әмма базарга барып җитә алмый. Чөнки юл өстендә елап утыручы бер баланы күрә. Пәйгамбәребез (сгв) аңардан:

- Балам, нилектән күз яшеңне түгәсең? - дип сорый.

- Мин ятим бер баламын. Минем әтием дә, әнием дә юк һәм шунлыктан мин бер байда коллыкта яшим. Бүген иртә белән минем хуҗам кулыма ике дирһәм тоттырып, кирәк-яраклар алу өчен базарга җибәргән иде. Мин исә юлда балалар белән уйнап ул акчаларны югалттым, шуның өчен елап утырам, - дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез (сгв) кесәсендә булган ике дирһәмен чыгарып, шушы балага тоттыра. Әмма нигәдер бу бала елавыннан туктамый. Пәйгамбәребез (сгв) янәдән:

- Нигә елыйсың? - дип сорый.

- Хуҗам, минем соңга калып, бернәрсә дә ала алмаганым өчен бик каты ачуланачак. Кыйнарга да мөмкин, шуңа күрә елыйм, - дип җавап җавап бирә ятим бала.

Пәйгамбәребез (сгв), баланы җитәкләп, аны озата китә. Бу баланың коллыкта яши торган йортына барып җиткәннән соң, Пәйгамбәребез (сгв) ишеккә шакып, каты тавыш белән: "Әссәламегаләйкем", - дип әйтә. Әмма ишекне беркем дә ачмый. Пәйгамбәребез (сгв) ишеккә өченче тапкыр каккач һәм эндәшкәч кенә ишек ачыла. Пәйгамбәребез (сгв) ятим баланың хуҗасыннан:

- Ни өчен беренче тапкыр эндәшкәч үк ишекне ачмадыгыз, әллә ишетмәдегезме? - дип сорый.

- Юк, Аллаһның илчесе, ишетүен ишеттем. Ишекне ачмавымның сәбәбе исә синең мөбарәк тавышың минем йортымда тагы ике мәртәбә яңгырасын дигән сәбәптән булды. Әй Аллаһның илчесе, бу ятим бала синең кебек - ягъни Аллаһка якын бер бәндә - өемә килүгә сәбәпче булганы өчен, аны коллыктан азат итәм һәм үз балаларыма биргән тәрбияне аңа да бирәчәкмен дип вәгъдә бирәм, - дип җавап кайтара хуҗа кеше.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, югарыда бәян кылынган вакыйганы укыганнан соң, киң күңелле кешеләрнең күзләре ихтыярсыз яшь белән тула. Әлбәттә, Мөхәммәднең (сгв) кешеләргә карата миһербанлы һәм шәфкатьле булуы һич авырсынмыйча өстендәге соңгы күлмәген салып бирә алуда күренә - бу аның пәйгамбәр икәнлеген кат-кат раслый һәм дәлилли. Чыннан да, аның йөрәгендәге мәрхәмәтлелек уты Аллаһы Тәгалә яраткан галәмнән дә киңрәк. Шундый шәхесләрнең исемнәре һәм тормыш үрнәкләре Кыямәт көненең ахыргы сәгатенә кадәр яшәячәк: ул чын мәгънәсендә яхшы мисал эзләүчеләргә үрнәк булачак. Мөхәммәднең (сгв) тылсымлы сүзләре - һичкем тарафыннан кабатланмас тормыш үрнәкләре - безгә пәйгамбәребезне (сгв) сөяргә һәм яратырга мәҗбүр итә. Ә инде сөю хисләре - сөелгән кеше артыннан иярүгә китерә. Әйе, без аның кебек була алмасак та, "Булдыра алмыйбыз" дигән булып, мөмкин кадәр мәрхәмәтлелек дулкынын таратудан ерак булырга тиеш түгелбез.

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН,**
**Казан шәһәре казые,**
**Борисководагы Шамил мәчете имам-хатыйбы**

# Пәйгамбәребезнең (сгв) нәфис теле

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

ләкин гаять зур мәгънәгә ия булуы белән аерылып тора, югары сәнгать үрнәге, чиста һәм табигый иде. Ул Аллаһы Тәгалә Үзе әйткән кебек иде:

"(Рәсүлем), әйт син:

- Бу эшләрем өчен мин сездән һичбер түләү таләп итмимен. Вәхий ителгәннәрдән башка, үзлегемнән мин һичбер нәрсә уйлап чыгармыймын, - диген" ("Сад (Даут) сүрәсенең 86 нчы аяте").

Ул һавалы ораторлыкны яратмаган, күп сөйләп, акыл сатып йөргән кешеләрдән читтә торырга тырышкан; аңлаешлы һәм кыска итеп сөйли торган булган. Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сәер әйберләр турында сөйләмәгән, ә базар кулланылышында булган тиргәш сүзләрне бөтенләй кулланмаган. Аның һәр сүзе хикмәт булган. Аның сөйләме сафлык белән уратып алынган булган, ул бөеклек белән кече күңеллелек, йомшак мөгамәлә итүне берләштергән, кабат аңлатуларга мохтаҗ булмаган, анда бер генә дә артык сүз дә кулланылмаган. Ул сөйләгән вакытта ялгышмаган, аның сүзләре кире каккысыз дәлилләр белән тулы булган; аның сүзләре бәхәскә урын калдырмаган, бәхәскә кергәннәрне дә бик озынга киткән гәпләрне дә, ул кыска гына, барысына да аңлаешлы, бары тик хак сүзләрдән генә торган телмәр белән туктата алган. Һәрвакытта хакыйкатьнең өстен чыгуы өчен тырышкан, һәм бу очракта үзенең абруеннан файдаланмаган, җавап бирүдән дә читтә калырга тырышмаган. Ул гайбәт сөйләмәгән, беркемне дә яманламаган. Аның сөйләменең тизлеге бик акрын да, бик тиз дә булмаган, ул буш сүзләр дә сөйләмәгән, башкаларга басым да ясамаган. Кешеләргә аның сүзләреннән дә файдалырак сүзләр ишетергә туры килмәгән. Аның сүзләре тәртипкә салынган, матур, ихтирамлы, аңлаешлы, җиңел, нәфис һәм күпкырлы булган.

Әл-Кази Гияз әйткән: "Матур теллелеккә һәм сөйләм осталыгына килгәндә исә, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иң югары урында тора, аның сөйләме башка кешеләргә билгеле булмаган дәрәҗәдә йомшак иде, сүз сөйләргә ул тиңсез оста иде. Сүзләре кыска, тәэсирле, тирән мәгънә һәм акыл белән тулы, табигый иде. Ул гарәп теленең шивәләрен белә иде. Һәр кабилә белән аның шивәсендә сөйләшә торган иде, кайбер сәхабәләр дә, хәтта теге яки бу кабиләдә кулланылган кайбер сүзләрне аңлатуны сорап, Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мөрәҗәгать итәләр иде", - дигән.

## Кыска һәм күркәм сөйләүгә мисаллар

Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөйләменең гадилеге, хикмәтлелеге һәм кыскалыгы турында җыентыклар язылган, аларда сүзләр һәм аларның мәгънәләре берләштерелгән; алар белән ярышу мөмкин түгел. Менә ул кайбер гыйбарәләр:

● Бар кешеләр дә, тарак тешләре кебек (тигезләр).

● Кеше үз яратканы янында булыр.

● Синдә күргән (ялгышлыкларны) сиңа әйтмәгән кеше белән дуслашуда мәгънә юк.

● Үз кадерен белгән кеше һәлак булмас.

● Кем киңәш итә, шул хәвефсезлектәдер.

● Яхшылык сөйләгән кешегә (бакыйлыкка әзерләнгән кешегә) - Аллаһ рәхимшәфкатен бирсен, ә кемдер эндәшми кала икән, үзен саклап калыр.

● Ислам кабул итсәң, котылырсың.

● Ислам кабул ит, Аллаһы Тәгалә сиңа икеләтә бирер.

● Ул үзенә кагылмаган әйберләр турында сөйли, ә үзенә хаҗәт булмаган әйберләргә саранлана.

● Өстә торган кул (бирүченең кулы) аста торганнан (алучыныкыннан) яхшырак.

Аллаһы Тәгалә үзенең Пәйгамбәренә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) кодрәт, ачык акыл, бөеклек һәм сүз күркәмлеге бүләк иткән. Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) кеше аңына килерлек тә булмаган гыйлем тулы иңдерелгән вәхиләрне кабул итү могҗизасына ия булган. Аның сүзләре муенсага тезелгән энҗе бөртекләре кебек мәгънә төсмерләренең төгәллеге белән аерылып торган.

## Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөйләменең үзенчәлекләре

Мисыр әдәбиятчысы Мостафа Садыйк әр-Рафигъ (1880-1937) Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөйләме уникаль һәм табигый булган, дип яза. Тел ягыннан караган вакытта, аларның үз юнәлеше булган, алар төгәл әңгәмә барган темага гына караган булганнар. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөйләмендә җөмләләр төгәл конструкция тәшкил иткәннәр, җөмләнең һәр өлеше бер-берсенә туры килгән. Җөмләләре тулы булган, сүзләренең үз мәгънәләренә бәйлелеге анык күренеп торган. Һәрбер аваз, һәрбер сүз ашыкмыйча, дулкынланмый гына әйтелгән. Алар сөйләм темасына төгәл туры килгәннәр, эчтәлектәге мәгънәгә каршы килмәгәннәр һәм иң кулайлары булганнар. Җөмләләрне бәян итүнең ачыклыгы ягыннан караган вакытта, алар күпмәгънәле, тәртип белән урнаштырылган булганнар, ачык чикләргә, гүзәл тасвирларга, гаҗәеп күрсәтмәлеккә ия булганнар һәм гадәттән тыш аңлаешлы булганнар. Аның сөйләме биздерә, ялыктыра торган да, мескен, ярдәмгә мохтаҗ кеше сөйләме кебек тә, ике төрле аңларга юл куя торган да булмаган, ул дулкынланмый гына, буш сүзләр кулланмый гына сөйли торган булган. Шуның өстенә тагын, аның сүзләрендәге мәгънә бөекле дә өстәлгән. Аның сөйләмендә сүзнең мәгънә катламнарының бар серләре дә, ачык итеп аңлата белү һәм зирәклек белән бергә берләшкән булган.

Акыллы кеше өчен ишарәләп бер әйтү дә җитә.

***Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ,***
***Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые,***
***Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе***

# Әбелмәних Каргалыйның суфичылык шигъриятендә Коръән мотивлары

**Совет чоры вакытында дингә карата урнашып калган методологик стереотиплар, психологик тискәре карашлар бүгенге көнгә кадәр дә бетмәгән әле. Кызганыч, фәнни тикшеренү әдәбиятында суфичылыкны "Урта гасырлар феодаль җәмгыяте өчен хас агым" буларак, бар алдынгы һәм мәгърифәтле идеяләргә каршы куеп күрсәтүләр дә җитәрлек.**



Мәсәлән, суфи шагыйрьләр иҗаты турында язган вакытта, кайбер авторлар аларның суфичылык юнәлешендәге эшчәнлекләрен, алар яшәгән заман йогынтысы, ул вакыттагы тарихи вазгыять һ. б. белән аңлатырга тырышалар. Һәм, шул ук вакытта, акланган кебек, алар хезмәтләренең "прогрессив" якларын да билгеләп китәләр. Андый караш тамырдан дөрес түгел, чөнки суфичык, әдәбияттагы дини-фәлсәфи агым буларак, Идел буе һәм Урал халыкларында фәлсәфи фикер барлыкка китерүдә, һәм шул ук вакытта, татар халкы тормышының катлаулы чорларында милли үзаңның сакланып калуы һәм үсешендә гаять зур роль уйнаган. Шул ук вакытта, суфичылык - ул пассив, аскетизмга чакыра торган (тәрк әд-дөнья) тәгълимат дигән фикер дә таралган. Монысы да хакыйкатькә туры килми, чөнки "тәрк әд-дөнья" мотивы рухи кыйммәтләрнең матди кыйммәтләрдән өстенрәк булуын гына максат итеп куя. Бу тәгълимат тарафдарлары иҗтимагый тормышта шуңа да актив позициядә торганнар. Башкача булырга да мөмкин түгел, чөнки тарихның катлаулы, чуалчык моментларында хакимият белән компромисска бару, аның белән конфронтациягә караганда, өстенрәк булган.

Нәкышбәнди (икенче төрле - нәкшибәндия) тарикатенең төп үзенчәлеге шунда: ул бар суфи мәзһәбләре арасында хакимият белән хезмәттәшлек итәргә чакырган бердәнбер юнәлеш булган. "Хаҗи Әхрар заманыннан бирле нәкышбәндия - хакимият белән аралашуны мөмкин генә түгел (мәсәлән, сөхрәвәрдия тарикатендәге кебек), ә бәлки, "аларның күңелен яулап алып", халыкка карата алып барылган сәясәтләренә йогынты ясау өчен зарури дип тә исәпләгән бердәнбер юл булып торган. Алар хакимият белән контактка кереп, "аларның күңелләрен яулап алып, аларның халык массаларына карата алып барылган сәясәтенә йогынты ясарга теләгәннәр" (Ислам: Энциклопедический словарь. - М., 1991. - С. 188). Идел-Урал төбәге суфичылыгы өчен хас булган сәяси активлык дәрәҗәсе шуннан чыгып аңлатыла да.

Хәзерге татар әдәбиятын тикшерү фәненең иң актуаль мәсьәләләренең берсе - суфи шагыйрьләрнең иҗатын нәкъ менә шул позицияләрдән яктырту да инде.

XIX гасыр Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), Әбелмәних Каргалый (1782-1833 елдан соң), Һибәтулла Салихов (1794-1867), Шәмсетдин Зәки (1825-1865), Гали Чокрый (1826-1889), Әхмәтҗан Тубыли (1825-189?) һ. б. суфи шагыйрьләр исемнәренә бай. Сәләтле каләм осталарының мәшһүр бу плеядасында Ә.Каргалый (чын исеме - Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов) исеме дә күренекле урын тота.

Шагыйрьнең бүгенге көнгә кадәр сакланып калган хезмәтләре күп санда түгел. "Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди" ("Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди хаҗи тәрҗемәләре") - шуларның берсе. Ул ун мөселман изгесенең тормыш юлы турындагы хикәятләрдән тора. Алар имам әл-Газәлинең "Тәфсире кәбир" ("Олы тәфсир") һәм "Мишкател әнвәр" ("Нурлар чыганагы") китапларының шигъри тәрҗемәләре. Кызганыч, суфи шагыйрь Ә.Каргалыйның иҗаты бүгенге көндә бик аз өйрәнелгән.

Әй, ничә мәгънәдә улан кур вә кәр!
Җан илә җәмгъ әйләюбән сим вә зәр,
Хак өчен вирмәя коругъ нанына,
Кәндүя даккан мөхибләр намыны!
Баглаюбән ишекене бәрк идәр,
Әнбияләр сөннәтене тәрк идәр.

[О, насколько глухи,
слепы поколения людей!
Душой и телом предаваясь
накопительству злата-серебра,
Не дав и корки хлеба на подаяние
Бога ради,
Они навешали на себя святые имена!
Закрывши плотно двери своих домов,
Отошли они от Сунны Пророка.]

*(Монда һәм алга таба авторның юлдан юлга тәрҗемәләре бирелә.)*

Татар шагыйренең бу юллары мәгънәсе буенча Коръән аятьләре белән бер яңгырашта: "Алар чукрак, телсез, сукыр. Алар инде (тугры юлга әйләнеп) кайтмаслар" ("Бәкара (Сыер) сүрәсенең 18 нче аяте"); "Көфер иткәннәрнең хәле, чакырып кычкырган авазны ишетеп тә сүзләрнең мәгънәсен аңламаганнарныкы кебек. Алар (кяферләр) телсез-чукрак, сукыр кебек. Шуңа күрә, аларның башы уйлар дәрәҗәдә түгел. (Аять иске карашларга ябышып ята торган, яңа фикерләрне кабул итәр дәрәҗәдә булмаганнарга ишарәле. Инҗил, Тәүрат һәм башка китапларны үзгәртеп язганнан соң, шул китапларга гына табынып яшәүчеләр Коръәннең яңа фикерләрен кабул итә алмый.)" ("Бәкара (Сыер) сүрәсенең 171 нче аяте"). "Саңгыраулар", "телсезләр", "сукырлар" сүзләре Коръәни-Кәримдә күп тапкырлар очрый; алар, чынлыкта, мөселманнар-

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Замана афәте

**Бер көнне авылыбызның Сабан туе чишмәсенә юл тотарга туры килде. Су салырга дип алынган савытларны машинадан чыгарып, әкренләп кенә чишмә капкаларына киттем. Әлеге урыннан ерак түгел машина эчендә урта яшьләрдәге ике ханымның утырганын күрдем. Үтеп барышлый аларга карасам, ни күрим: икәүләшеп, посып сыра чөмереп утыралар икән! Икесе дә саф татарча сөйләшәләр!**



Инде яңа килгән хәзрәтне азрак таный да башлаганнар бугай, мине түбәтәйсез килеш тә күреп, стаканнарындагы агуны тиз генә йотып бетерделәр дә, савытларын артка суздылар. "Әллә өчәүләшеп салалар инде!" - дигән фикер килде башка.

Ләкин, минем гаҗәпсенүемә чик булмады - арткы ишектән 30 яшьлек хатын чыкмады, анда 10 яшьләр тирәсендәге сабый пәйда булды. Кулында - зур (2 литр чамасы), яшел төстәге сыра шешәсе һәм ике стакан белән чипсы пакеты. Сабый шуларны тиз генә чүплек контейнерына салды да, анасының машинасына кереп утырды. Бу ике ханым мине таныганнан соң, ачулы кыяфәт белән машиналарын кабызып, авылга сыздылар.

Менә шундый хәлләрне һәрберебезгә дә еш күрергә туры килә. Хатын-кызлар Аллаһы Тәгалә хәрам кылган эчемлекләрне хәзер ир затыннан да күбрәк эчәләр! Тәмәкесен дә күбрәк тарталар! Милләтебез өчен бу бик зур һәм куркыныч афәт, моннан безгә бер кайгы булыр. Шуның өчен кырыйдан гына карап тору кирәкмәс, эшләргә, хатаны төзәтергә кирәктер.

Андый хатыннарны хурларга, гакылга китерергә кирәк. Ул бит ана кеше, кемдер өчен газиз әнкәй. Бу чуалган гакылны хикмәтле рәвештә туктатыйк. Әйе, миңа шул вакыт бәйләнсәгез дә була: "Ул сыра гына бит эчә - аракы түгел!", "Алкашка түгел бит ул!", "Авыр эш көне булды - расслабиться итәргә кирәк!" кебек сүзләрне кайбер хатыннар үз оятсызлыкларын агарту өчен әйтергә мөмкиннәр.

Сөйләгез, сүгегез, ләкин... бина ничек бер кирпичтән салына башласа, эчүчелекнең дә башы бер тамчыдан башлана, ә соңрак эчкечелек бинасы барлыкка килә. Әлеге бина биеккә үскән саен кеше аннан җиңел генә төшә алмый, бары тик сикерә генә ала. Күпчелеге түзә алмыйча сикерергә мәҗбүр була да инде. Ә бит барысы да бер йотымнан башлана...

Ошбу беренче йотымны туктата алсак, балаларга аның хакында нәсыйхәтләр сөйләп, аларны тәрбияви юлга чакыра алсак - менә бу зур җиңү булыр. Ләкин, шул көрәшүдә шайтан үз ялганын кертә - ул хәрам эчемлекне халык күзлегендә дәрәҗәләргә бүлә: монысы җиңелчә исертә, монысы - уртача, ә монысы бөтенләй башка шәп бәрә. Бу ялган хакында Пәйгамбәребезнең (сгв) бик хикмәтле хәдисе бар: "Кыямәт башланыр алдыннан кешеләр хәмергә башка исемнәр кушып эчәрләр". Әйе, хәзерге заманда шулай эшлиләр дә: "Аракы - ул ирләр эчемлеге, аны тәрбияле хатыннар эчми, алар өчен шампанский бар", - дип, шайтан һәрберебезнең башына низамын сала. Сыра, шәраб, шампан, ликёр, джин һ. б. "Бу бит аракы түгел, сыра гына", - дип ата баласына шешә суза.

Бүгенге көндә кешелеккә каршы булган террорчылык, наркотиклар, СПИДка каршы күпме көрәш бара, әлхәмдүлилләһ, барысы кирәк. Әмма шуның аркасында кайгыга дучар булганнарның барысын бергә кушсаң, барыбер бу яшел елан - аракы-шәраб корбаннары кадәр булмыйдыр. Бу афәттән дөньядан үтүчеләр санын әйтеп бетерерлек түгел!

Хәмернең бер тамчысын куллану сәбәпле Аллаһ кешенең иманын кырык көнгә салдырып ала, аның бер догасын да кабул итми, аңардан читләшә. Мин тап булган чишмә янында салучы хатыннар сабыйлары өчен дога кылалар, бәхет сорыйлар, тик Аллаһы Тәгалә аларның сораган әйберләрен бирер микән?! Әллә оятсызлык кылып йөргән аналарга балалары аша хәсрәт белән кайгы гына җибәрерме?

**Аллаһ безне бу афәттән Үзе сакласа иде.**

*Хәбир хәзрәт ХАНОВ,*
*Чирмешән Җәмигъ*
*мәчете имам-хатыйбы*

# Пычрак гайбәтләр корбаны булдым...

СОРАУ-ҖАВАП

***Мин югары уку йортында белем алам, анда мөселманнар азчылыкны тәшкил итә. Бөтенесе белән дә яхшы мөнәсәбәттә булырга тырышам, ләкин күптән түгел генә минем дошманнарым барлыкка килде. Алар минем турыда гайбәт тарата башлады. Моны белгәч, мине ачу басты. Бу гайбәткә башкаларның ышануы мине үтерде дияргә була. Минем белән бары тик ике чын дустым гына торып калды, башкалар гайбәткә иярде. Мин тирән депрессиягә бирелдем. Депрессиядән чыгарга миңа догалар да ярдәм итми.***

***Бу бер ел чамасы дәвам итә, мин әле дә укырга барганда бик дулкынланам, миннән барысы да көләләр, гаеп итәләр сыман. Кемнеңдер көлгәнен күрсәм, миннән көләләрдер шикелле тоела. Бу депрессиядән ничек чыгарга микән? Киңәш итсәгез иде: моны ислам дине ярдәмендә башкарып буламы? Кешеләрнең көлүенә игътибар итмәскә өйрәтсәгез иде, зинһар.***

**Сезнең соравыгызга дини күзлектән Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые Руслан хәзрәт Мортазин җавап бирә:**

– Хәдистә гайбәтчеләрнең җәннәткә кермәве турында әйтелә. Әгәр дә ул тәүбәгә килсә, җәннәткә иң соңгы булып керәчәк. Гайбәт сөйләү – зур гөнаһ. Соңгы вакытта килеп чыккан җәнҗал һәм дошманлык күбесенчә гайбәтчеләр аркасында барлыкка килә. Депрессиядән котылырга сезгә догалар, Аллаһы Тәгаләгә ялвару һәм гыйлем булышачак. Даими рәвештә намаз укыгыз, намаздан соң дога кылыгыз, Аллаһы Тәгаләдән гайбәттән саклавын сорагыз һәм ислам дине буенча гыйлем туплагыз. Гыйлем – ике дөньяда да бәхеткә ирешү юлы. Нәкъ менә гыйлем сезгә мондый нәрсәләргә гади карарга ярдәм итәчәк: әгәр дә кемдер сезнең турыда гайбәт сата икән, сезнең гөнаһларыгыз кичерелә. Чынлыкта исә безне күбрәк үз гөнаһларыбыз, Аллаһы Тәгалә алдында тоткан урыныбыз борчырга тиеш. Без кимчелекләребезне яхшы якка үзгәртү турында уйланырга тиешбез. Сүзебез һәм гамәлләребез белән дә Рәсүлебез Мөхәммәт (сгв) юлыннан барырга тиешбез. Аллаһы Тәгалә безне ярдәменнән ташламаса иде. Әмин.



## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 8.12.12 | 7:30 | 9:00 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Якшәмбе | 9.12.12 | 7:31 | 9:01 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Дүшәмбе | 10.12.12 | 7:32 | 9:02 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Сишәмбе | 11.12.12 | 7:34 | 9:04 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Чәршәмбе | 12.12.12 | 7:35 | 9:05 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Пәнҗешәмбе | 13.12.12 | 7:36 | 9:06 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Җомга | 14.12.12 | 7:37 | 9:07 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Шимбә | 15.12.12 | 7:38 | 9:08 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |

## Әбелмәних Каргалыйның суфичылык шигъриятендә Коръән мотивлары

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

ның Китабы аңлатуы буенча, (хакыйкатькә) чакыруларга - саңгырау, (хакыйкатьне сөйләр өчен) телсез, (анык дәлилләрне күрер өчен) сукыр булган кяферләр. Ә.Каргалый иманда игелекле гамәлләр кылуга, якыннарыңа хезмәт итүгә зур әһәмият бирә. Шуңа да, аның "Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди хаҗи тәрҗемәләре" китабына кертелгән шигырьләрендә әхлакый эчтәлек өстенлек итә. Алар пәйгамбәрләр һәм тәкъвалар тормышын язу үрнәге нигезендә кешеләрдә иң яхшы сыйфатлар тәрбияләргә, аларны теләсә нинди сынауларны сабырлык белән, ләкин, шул ук вакытта, үз идеалларыңа тугрылык саклап калып кичерергә чакыралар. Бу җәһәттән, татар шагыйре уртача (умеренный) суфичылыкның күренекле тарафдары булып тора.

*Алсу ХӘСӘВНЕХ,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм*
*музыкаль мирасны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 23 (166) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9428.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 6 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**